СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

№ 1-34 | от 28 февраля 2024 года

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 1-32 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль

бәрәмлеге Уставының 89 статьясының 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге
Советы рәисе /Б.Ф.Хасанов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге Советының
28 нче февраль 2024 ел, № 1-34
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр

1. Уставның 5 статьясы 1 өлеше 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

2. 31 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 13 өлеш өстәргә:

«13. 13) Җирлек депутаты, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, коррупциягә каршы көрәш максатларындагы башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны жайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декбрендәге 273-ФЗ Федераль законның 13 статьясындагы 3 — 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аннан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».;

3. Уставның 34 статьясындагы 1 өлешенең 27 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«муниципаль хокукый актларны игълан итү, җирлектә яшәүчеләргә рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

4. 44 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 5.2 өлеш өстәргә:
«5.2. Җирлек башлыгы, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, коррупциягә каршы көрәш максатларындагы

башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны жайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декбрендәге 273-ФЗ Федераль законның 13 статьясындагы 3 — 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аннан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».;

5. 2 пункта 8 части 1 50 статьяның 1өлеше 8 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

6. Уставның 64 статьясының 1 өлешендә:

6.1. 1 пунктка «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

6.2. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру яисә, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру;»;

7. Уставның 64 статьясының 2 өлешендә «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;.

8. 72 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«72 статья. Муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе һәм игълан ителүе

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр карарда башкасы билгеләнмәсә, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланганнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Җирлек советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

Җирлек Советының Уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлары Федераль законнар, әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгының, җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең, җирле үзидарәнең башка вазифаи затларының хокукый актлары, әгәр актлар белән башкасы билгеләнмәгән булса, алар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Муниципаль хокукый актлар, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә торган салымнар һәм җыемнар турында җирлек Советының норматив хокукый актларыннан тыш, җирлек Уставында билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

4. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

5. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне, игълан итү тәртибе Поселения Уставы белән билгеләнә һәм, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, гражданнар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

6. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru ФС77-60244 номерлы ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яки Мамадыш районының «Вятка» газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык; ПИ по ФС7-4738 от 30.11.2007 массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә законнарның үтәлешен күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе)

2) рмуниципаль хокукый актны чикләнмәгән затлар даирәсе өчен мөмкин булган урыннарда (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында, йөрү өчен мөмкин булган башка урыннарда) урнаштыру;

3) муниципаль хокукый актны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru//) урнаштыру»;

7. Муниципаль хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми басмасы булып аның тулы

текстының беренче басмасы Мамадыш районы газетасында Вятка (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) санала.; ПИ №ФС7-4738 от 30.11.2007 массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә законнарның үтәлешен күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе) яки аның тулы текстын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында беренче тапкыр урнаштыру (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-60244 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән.

8. Әгәр муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми рәвештә бастырып чыгару Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында гамәлгә ашырыла икән (pravo.tatarstan.ru), торак пунктта 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә «дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турында» урыннарда «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә тоташтыруның бер яки берничә пунктын булдыру тәэмин ителә., аларны чикләнмәгән кешеләр (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында, башка урыннарда) өстәмә техник чаралар кулланмыйча куллана ала».

9. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».